ИЛ САКЧЫСЫ

Россия Оборона министрлыгы Әгерҗе егете Сергей Гугалоның батырлыгы турында хәбәр итте

> 2

СОҢГЫ СЕЗОН

Татарстанның халык артисты Раушания Юкачеваны соңгы юлга озаттылар

> 3

ҖӘЙ БЕТТЕМЕ?

Быелгы Питрауның күңелле мизгелләре – безнең репортажда

> 4

ӨЧ ОЧКО

«Рубин» 20 елдан соң кабат беренче лигада уйный башлады

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 102 (28875) | Сишәмбе | 19 июль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ҖИРНЕҢ КАДЕРЛЕ ЧАГЫ

Яңалык

Татарстанда күпбалалы гаиләләргә бирелә торган җирне алу тәртибе үзгәрде. Элек аны Татарстанда пропискада булган һәр гаиләгә бирәләр иде. Моның өчен аларның күпбалалы булып исәпләнүләре һәм пропискада булулары җитә иде. Хәзер башкача. Бушлай җир кишәрлеге алу өчен гаиләнең торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булып исәптә торуы һәм ир яки хатынның Татарстанда кимендә биш ел пропискада булуы кирәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Исегезгә төшерәбез: федераль закон буенча Җир кодексына һәр төбәк үзгәреш кертергә хокуклы. Шуңа нигезләнеп, Дәүләт Советы депутатлары Җир кодексына төзәтмә кертте. Республикада җир кишәрлекләре җитми. Әнә шуңа да хәзер аны торак алуга мохтаҗ саналган гаиләләргә генә бирәчәкләр.

Татарстанда, 2022 ел башына алынган мәгълүматлар буенча, 66 меңнән артык гаилә бушлай бирелергә тиешле җир кишәрлеген көтә. Күпбалалы гаиләләр өчен кадастр исәбендә 45 меңнән артык җир участогы куелган. Татарстан Дәүләт Советы депутаты, Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты җитәкчесе урынбасары Таһир Һадиев республикада җиргә кытлык икәнен инкарь итми. Әлеге проблема аеруча Казан, Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама кебек зур шәһәрләрдә күзәтелә икән.

– Җир – резина түгел. Татарстан Идел буе төбәкләре арасында күпбалалы гаиләләр саны буенча беренче урында тора. Сер түгел, күпбалалы гаиләләр арасында бай тормышта яшәүчеләр дә бар. Хәзер төзәтмәләр кертелгәч, җир мохтаҗ гаиләләргә бирелә башлаячак. Болай эшләгәндә, беренчедән, кешеләрнең социаль ягы кайгыртыла, икенчедән, чират кыскара, – ди Таһир Һадиев. – Мохтаҗ гаиләләргә җир бушлай бирелә. Әлеге җирне йорт салыр өчен, бакчачылык белән шөгыльләнү, ярдәмче хуҗалыклар тоту өчен дә файдаланырга мөмкин.

«Татарстанның күпбалалы гаиләләре» иҗтимагый оешмасы рәисе Артем Кузнецов законга кертелгән үзгәрешләр белән килешеп тә бетми.

– Күпбалалы гаиләләргә җир бирү турындагы законны 2011 елда Дмитрий Медведев Россия Президенты булган чакта кабул иткән иде. Ул шул вакыттан бирелә инде. Әмма Казан, Чаллы кебек зур шәһәрләрдә, чынлап та, җир җиткерә алмыйлар, – ди Артем Кузнецов. – Бездә күпбалалы гаиләләр өчен җир генә түгел, фатир алуда да проблемалар бар. Татарстанда биш бала үстерүче гаиләләр торак шартларын бушлай яхшырта ала. Элек биш бала һәм әти-әнисе белән кечкенә фатирда яшәүче гаиләләргә дәүләт зуррагын биреп, аларның искесен үзенә ала иде. Әмма фатирлар озак төзелде, монда да хәзер зур чират барлыкка килде. Фатирларны да мохтаҗ булган гаиләләргә бирә башладылар. Аларның милеген, каядыр тик яткан җирен исәпләгәч, бу гаиләләрнең күбесе фатирсыз да калды. Узган ел 35 гаилә фатир алыр дип көткән идек, 22сенә генә бирелде. Татарстанның Төзелеш министрлыгы моны чималга бәя арту белән аңлата.

Артем Кузнецов мохтаҗ кешегә җир биреп, ул анда ничек төзелеш алып бара алсын инде дигән фикердә. Йорт салырлык хәле булса, җирен дә таба алар, янәсе. «Әгәр күпбалалы гаиләгә җир бирелеп тә, анда төзергә, ул урында инфраструктура булдырырга ярдәм итмиләр икән, ул урыннар тик кенә ятачак. Кайда хакимият эшли, шунда йортлар салына. Күпбалалы гаиләне шәһәр читенә илтеп урнаштырып кына эш бетми», – ди ул.

Казанда яшәп, Биектау районының Каймар авыл җирлегенә караган урыннан кишәрлек алган гаиләләр шактый. Эльяра Зәйнуллинага җирне өченче баласы тугач биргәннәр. Әмма бары тик уты гына кертелгән кишәрлектә алар берни төзи алмаган.

– Төзелеш эшләре башланса дип, без анда мунча җиткереп куйган идек. Янәсе, юынып чыгар җир булсын. Әмма ни газы, ни суы, ни юлы булмады. Инфраструктуралы җир булса, рәхәтләнеп яшәр идем. Без инде дәүләт биргән җирне оныттык. Үзебез башка урыннан кишәрлек сатып алып, йорт төзи башладык. Ичмаса, ул җирләрне авыл эченнән бирмиләр бит. Теләсә кайсы авылга кайтып йөрер идек, җәйләрен шунда яшәр идек. Депутатлар шунысын да уйласын иде, – ди ул.

Артем Кузнецов та, күпбалалы гаиләләргә җир биреп, андагы төзелешне күзәтеп, ут-су, газ белән тәэмин итүче районнар сирәк, ди. Бу аңлашыла да: зур шәһәрләрдә яшәүчеләргә җир районнарда бирелә, ә алар исә ул мәйданнарны әзерләп җиткерә алмый, моның өчен акча да юк. Кузнецов бу җәһәттән Кукмара районын үрнәк итеп куя. Анда инде йортлар төзелеп, күченеп яшәүчеләр шактый икән.

Без Кукмарада яшәүче күпбалалы әни Ләйсән Фәттахова белән сөйләштек. Алар өченче бала туганчы әти-әниләре белән яшәгән. Сабыйлары тугач, җир алырга чиратка басканнар. Узган ел йортларын җиткереп күченгәннәр. Ләйсән дәүләтнең мондый ярдәменә рәхмәтле. «Ишле гаиләгә зур булышлык бу. Җир сатып алып, йорт сала башласаң, шактый акча кирәк. Ә без бу акчага төзелеш материаллары алдык», – ди ул.

Кукмара районы авылларында да күп бала үстерүчеләргә җир бирәләр икән. Авылны бетермәс өчен дә бер дигән мөмкинлек бит бу! Вахит авылында яшәп, 5 бала үстерүче Айгөл Сәмигуллина үз урамнарында гына җир биргәннәренә сөенеп бетә алмый. «Шулкадәр матур урында бу җир. Әлегә без анда печән үстерәбез. Әмма киләчәктә йорт салырга исәп бар. Балалар үсеп килә бит, – ди ул. – Баланы үзебез өчен тапсак та, дәүләт ярдәмен тою рәхәт. Сабыйларның киләчәктә үз республикасына файда китерүчеләр булып үсүен телибез».

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Президент кушты

Россиядә яшәүчеләрнең уртача гомер озынлыгы 2030 елга кадәр 78 яшькә җитәргә тиеш. Стратегик үсеш һәм илкүләм проектлар буенча совет утырышында Президент Владимир Путин шундый бурыч куйды. Ул Россия табибларының коронавирус пандемиясенә каршы көрәштә зур уңышларга ирешүен ассызыклады. Икенче квартал йомгаклары буенча илдә үлем-китем күрсәткече пандемиягә кадәрге – 2019 елгы дәрәҗәгә калган. Ә гомер озынлыгы, беренче нәтиҗәләр буенча, 73 яшьтән арткан. Владимир Путин әйтүенчә, бу күрсәткеч кешеләребезнең тормыш шартларын яхшырту һәм сәламәтлеген ныгытуга бәйле. Ул шулай ук шикәр чире һәм С гепатитына каршы көрәш буенча программаларны тизрәк кабул итеп, аларны тормышка ашыра башларга кушты. «Гәрчә Хөкүмәткә әлеге бурыч инде күптәннән йөкләнсә дә, аның буенча эш һаман башланмаган әле», – дигән Президент.

Авыл мәктәпләрен җиһазландыралар

Республикада 1 сентябрьгә «Мәгариф» илкүләм проекты кысасында авыл мәктәпләрендә 117 «Үсеш ноктасы» үзәге ачыла. Аларда яңа уку кабинетлары пәйда булачак дигән сүз бу. Мәгариф һәм фән министрлыгының гомуми белем бирү идарәсе башлыгы Татьяна Алексеева әйтүенчә, нәкъ менә сала мәктәпләрендә укыту-лаборатория җиһазларын яңарту таләп ителә. 2018 елда тормыш иминлеге нигезләре, технология фәннәре, информатика буенча җиһазлар заманчаракларына алыштырылган, шахмат зоналары булдырылган. Ә инде 2020 елдан башлап мәктәпләр физика, химия, биология буенча яңа җиһазлар белән тәэмин ителә башлаган. «Бүгенгә нәкъ менә шушы фәннәр күз уңыннан читтәрәк калып килә. Җиһазларны яңартырга, ә укучыларга табигать фәннәре буенча мәгариф программаларын үзгәртергә кирәк. Тагын 117 «Үсеш ноктасы»н ачуның мәктәпләрдә бу фәннәрдән белем бирү сыйфатын яхшыртачагына ышанабыз», – ди Татьяна Алексеева.

Тормыш кыйммәтләнә

Татарстанда минималь куллану бюджетын 21,3 мең сумга җиткерү күздә тотыла. Бу җәһәттән Министрлар Кабинеты карары Хөкүмәт сайтында урнаштырылган. «Татарстан Республикасында 2022 елның II кварталы өчен минималь куллану бюджеты күләмен 21300 сум күләмендә билгеләргә», – диелгән документ проектында.

Исегезгә төшерәбез: минималь куллану бюджеты – кешегә иң кирәкле товарлар һәм хезмәтләр бәясе дигән сүз. Асылда минималь куллану кәрҗине бәясен чагылдыра. Республикада I кварталда бу күрсәткеч 19424 сумга тигез иде. Шул рәвешле ул 1876 сумга арта. Хәзер карар проекты коррупциягә каршы экспертиза уза. Экспертиза 15еннән 22 июльгә кадәр үткәрелә.

Яшәргә өйрәнәбез

Балта урынына шөшле булмасын

Халыкның нибары 40 проценты гына хакимият органнарыннан элемтә платформасы аша алынган җаваплардан канәгать. Татарстанда Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкил Сәрия Сабурская шулай дип белдерде.

Кешеләргә бигрәк тә түрәләрнең мөрәҗәгатьләрне карап тикшерүне озакка сузулары һәм җавапларның эчтәлеге ошамый. Вакытында җавап бирмәү буенча Дәүләт торак инспекциясе алда бара: ведомствога кире элемтә платформасы аша алынган 111 шикаятьнең 35енә бер айдан күбрәк вакыт узгач кына җавап җибәрелгән. Закон буенча, аны карап тикшерү срогы 30 көн тәшкил итә. Антирейтингта икенче урында – Сәламәтлек саклау министрлыгы (2958 мөрәҗәгатьнең 23енә вакытында җавап бирелмәгән). Муниципаль берәмлекләр арасында Бөгелмә барыннан да ныграк сынаткан: 232 мөрәҗәгать арасыннан 52сенә җавап вакытында юлланмаган.

Сәрия Сабурская әйтүенчә, Министрлар Кабинеты карарында халыктан алынган шикаятьләрне тикшерү срогы закондагыга караганда да кимрәк – нибары 10 көн. Моны исәпкә алсак, вакытында каралмаган мөрәҗәгатьләр саны бермә-бер арта.

Җавапларның сыйфатына килсәк, бу кадәресе бер генә мисалдан да аңлашыла. Әлмәт районында яшәүче бер ир-ат 5 һәм 5А маршрут автобусларының начар йөрүенә ризасызлык белдергән. «Автобуслар начар йөри, кичке җидедән соң бөтенләй күренмиләр. Тиз генә чарасын күрәсе иде», – дигән ул үзенең хәбәрендә. Шәһәр хакимияте аңа: «Транспорт эшендәге өзеклекләр техниканың торышы начар булуга бәйле, ә сорау башкарма комитетка түгел, ә транспорт оешмасы җаваплылыгына карый», – дип җавап язган.

– Кайвакыт балта сораганга шөшле тоттыралар кебек тә булгалый, – ди Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкил. – Тукай районында яшәүче ир-ат нәкъ менә шундый хәлдә калган. Ул чүп машинасының койманы аударып китүенә шикаять язып җибәргән. Ә аңа юлның бу өлешен 2023 елда төзекләндерергә ниятләүләре турында җавап юлланган. Еш очрый торган тагын бер җавап – «акча булгач, сезнең мәсьәлә хәл ителәчәк».

Сүз уңаеннан, элемтә платформасының Россия Дәүләт хезмәтләре порталында эшләп килүен искә төшерик. Узган елда ул Татарстанның «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына да кертелгән. Быел гыйнвар – июнь ае чорында «Халык контроле»ндә басылып чыккан һәр биш мөрәҗәгатьнең берсе нәкъ менә кире элемтә платформасы аша алынган.

Менә шулай, хакимият органнарына әкренләп кенә интернет аша халык белән аралашуга күчәргә туры килә. Төбәкне өйрәнү үзәге үткәргән сораштыру нәтиҗәләренә караганда, республикада яшәүчеләрнең 53 проценты социаль челтәрләрдә хакимият органнары җавапларын файдалы һәм кирәк дип саный. Шул ук вакытта Россия Президенты әле шушы көннәрдә генә дәүләт хакимияте органнарына һәм алар карамагындагы оешмаларга социаль челтәрләрдә үз сәхифәләрен алып баруны йөкләгән законга кул куйды. Татарстанда барлыгы 5638 оешма шушы закон таләбен үтәргә тиеш. Әлегә нибары 2795енең генә сәхифәсе бар.

– Социаль челтәрләр инде күптәннән күңел ачу чарасы булудан туктады. Халык белән аралашу, элемтә булдыру өчен иң мөһим мәйданчыкларның берсе бу. Хакимият органының социаль челтәрләрдә «утыруы» аның халыкка якын булуын күрсәтә. Шуңа күрә нindидер сәбәпләр аркасында моңа кадәр бу мәйданчыктан читләшеп йөрүчеләр әлеге эшкә инде якын араларда ук кушылырга тиеш, – дигән фикердә Сәрия Сабурская.

Сүзгә-сүз

Владимир ПУТИН, Россия Президенты:

Россиянең үсешен тоткарлау өчен алдыбызга киртә куярга маташалар. Әмма бирешергә, аптырап калырга яки, кайбер «дус»ларыбыз фаразлаганча, дистәләрчә елларга артка чигенергә җыенмыйбыз. Әлбәттә, юк! Киресенчә, алдыбызда нинди зур кыенлыклар торганын аңлаган хәлдә, тырышып, яңа чыгу юллары эзләячәкбез.

(Стратегик үсеш һәм илкүләм проектлар буенча совет утырышындагы чыгышыннан)

ТАТАРСТАН ХАЛКЫНЫҢ БАНКТА КҮПМЕ МАЯСЫ САКЛАНА?

Татарстанның Милли банкы мәгълүматларына караганда, республикада яшәүчеләр 769,4 млрд сум акчасын (эскроу-счетларны да кертеп) банкларда саклый. Ел дәвамында әлеге сумма 15,3 процентка арткан.



Рубльдә **(88,9%)**
684,4 млрд сум –
19 процентка арткан.

Чит ил валютасында **(11,1%)**
85 млрд сум –
8 процентка кимегән.

Печән исе

Республика кырларында терлек азыгы әзерләү дәвам итә. Авыл хуҗалыгы министры урынбасары Ленар Гарипов белдергәнчә, бүгенгә 387 мең тонна печән һәм 1 миллион 762 мең тонна сенаж хәстәре күрелгән. Республика буенча 1 баш терлеккә уртача 14 центнер азык туры килә. Бу – планда каралганның 35 проценты дигән сүз. Кайбыч, Бөгелмә һәм Чистай районнарында кирәкле күләмнең 50 процентыннан артыграк азык әзерләнгән. Әмма 14 районның күрсәткечләре республика буенча уртача саннан кимрәк. Әйтик, Яшел Үзән районының «Красный Восток» хуҗалыклары 1 баш терлеккә нибары 8,8 центнер гына азык әзерләп куйган.

Шәхси ярдәмче хуҗалыклар өчен терлек азыгы җыю дәвам итә. Бүгенгә ихтыяҗның 64 проценты күләмендә – 538 мең тонна печән хәстәре күрелгән инде. Мамадыш, Биектау, Чирмешән, Алабуга районнары авыл халкын печән белән тулысынча тәэмин иткән. Шул ук вакытта Апас, Лаеш, Кама Тамагы, Актаныш һәм Питрәч районнарына бу җәһәттән эшне көчәйтергә кирәк. Соңгы елларда нәкъ менә шушы районнарда шәхси хуҗалыкларда сыерларның баш саны кимүгә юл куелган.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ИРАН АТОМ БЕЛӘН ЯНЫЙ

Байденның Якын Көнчыгышка сәяхәте төгәлләнде. Үткән атна вакыйгаларына менә шул җөмлә белән бәя биреп була. Гарәп илләре дөнья сәясәтендә зур әһәмияткә ия көчкә әйләнеп баралар. Үзенең сайлау алды компаниясе вакытында Согуд Корольлеген читкә кагылган (изгой) илгә әверелдерергә вәгъдә биргәндә, АКШ лидеры, башын иеп, принц Мөхәммәд ибн Сәлмән каршына килермен дип уйламагандыр да. Нәкъ менә корольлекнең тәхет варисына ул кеше үтерүдә гаепләп янаган иде. Әмма дә ләкин дөнья сәясәтендә вазгыять хәзер шундый: гарәпләрдән башка аяк атлавы кыен. Байденга, принц даирәсендә утырганда, журналистлар маңгайга бәреп: «Корольлек һаман да читкә кагылганмы?» – дигән сорау бирделәр, Вашингтон лидеры дәшмәде. Бары тик соңыннан гына гарәпләргә карашы үзгәрмәвен әйтеп маташты. Согудләр белән очрашуның нәтиҗәсе болайрак: Әр-Рияд нефть чыгаруны арттырырга вәгъдә бирә. Илле процентлык арттыру турында сүзләр ишетелде. Аналитикларның күбесе моны дөрес аңламады. Корольлек хәзерге чорда 10 миллион баррель тирәсе «кара алтын» чыгара. Аңа илле процент өстәсә, Россия нефтенең кирәге калмас иде. Әмма эш алай түгел. Алдагы ике айда гарәпләр «кара алтын»ны болай да планлы рәвештә арттырачаклар иде. Менә шул арттырыла торган күләмгә генә илле процент өстиләр. Әйтик, йөз мең баррель өстәргә ниятләгән булсалар, хәзер йөз илле мең баррель итәләр. Бу ярыйсы, әмма Байден теләгәнчә күп түгел. 2027 елга гына җир маен суыртуны 13 миллион баррельгә җиткерү вәгъдәсе бар. Бу хәзергедән утыз процентка артык.

Байденның гарәп илләре буйлап сәяхәте шулай да нәтиҗәсез үк түгел. Берләшкән Гарәп Әмирлекләре Россия олигархларына каршы санкцияләргә кушылырга риза булды. Дөрес, бу очракта да тоталь эзәрлекләү турында сүз бармый. Гаепләре дәлилләнгән «яңа байлар» гына әмирлекләрдәге маллары белән хушлашачак.

Визит исә Тель-Авивтан башланды. Самолет трабыннан төшкәч, Байден үзенең ни өчен килгәнлеген кешеләрдән сорады, диделәр. Нишләтәсең, хәзер дөнья сәясәтендә акылын югалтканнар дилбегә кага. Израиль исә АКШны Иранга каршы сугышка өнди. Сәбәбе: фарсыларга атом бомбасы ясарга юл куймау. Тәһран исә гыйбриләрнең котын ала торган рәсми белдерү ясады. «Берничә көн эчендә без уранны 60 процентка кадәр баеттык һәм җиңел генә 90 процентка баета алабыз, – диде ил Президентының киңәшчесе Камаль Харрази. – Иранда атом бомбасы ясарга кирәкле техник чаралар пәйда булды», – дип тә өстәде.

АКШ белән Израильнең Иранга каршы зур сугышы булмас, дип исәпли газета хәбәрчесе. Ракеталар очып алырга ихтимал, әмма эш зурга китмәс. Зур сугыш бөтенләй башка мәйданнарда кабыныр. Глобаль икътисадның зур тетрәнү һәм селкенү стадиясенә кереп баруы бөек конфликтны котылгысыз итә. 2022 елны хәзерге дәрәҗәдәге киеренкелек белән төгәлли алсак, бу зур уңыш булачак. Бер генә сөенечле фараз ясый алабыз: масштаблы атом-төш конфликты булмас.

Россиядә

ЧЕБЕШЛӘРНЕ КӨЗЕН САНАРБЫЗМЫ?

Россиянең икътисади һәм социаль тормышында һаман да билгесезлек хөкем сөрә. Якын киләчәктә нефть бәяләренең ничек булачагын без белеп бетермибез. Ливия – фетнәдән айный алмый интеккән Төньяк Африка иле – «кара алтын» чыгаруны ике тапкыр арттырырга вәгъдә бирә. Хәзерге углеводородлар базарындагы киеренке хәлдә Ливиянең нефть сатудан туктавы да үз ролен уйный. Триполи базарга яңадан үз нефте белән әйләнеп кайтса, җир мае арзанаерга да мөмкин. Хәзер дә аның бәясе 100 доллардан түбәнгәрәк китеп ала. Россиягә углеводородлар экспортының зур акча китерүе әлегә безгә муллык вәгъдә итми, чөнки хәтта Һиндстан – Россиянең төп тышкы базарларының берсенә әйләнеп баручы ил – бездән алуны арттыра, үзенекен сатуны киметә. Апрель – май айларында Россиянең Һиндстанга экспорты 272 процентка үскән, импорт исә 46 процентка кимегән. Хәлнең менә мондый торышы безнең эчке базарларга киеренкелек өсти.

Россиядә «санкция кризисы»ның «борылыш пункты» өченче – дүртенче кварталларда булыр, дип саный Макроикътисади анализ һәм кыска сроклы фаразлау үзәге (ЦМАКП) белгечләре. Алар чит илләрдәге инфляция безгә дә килер, тышкы сәүдә катлауланыр, компанияләр персоналны кыскартыр дип саныйлар. 2022–2023 елларда экспорт масштаблы рәвештә кимер, дип тә өстиләр. Ә менә импорт, шартларга ияләнә төшкәч, шактый гына артыр дигән фараз да бирәләр. Ләкин технологияләр һәм технологик җиһазлар импортлап булмау сәбәпле, халык куллануы товарларын күпләп сатып алу үзебездә җитештерүгә аяк чалыр дигән шик тә белдерәләр.

Илнең рәсми даирәләре дә алдагы айларның катлаулы буласын таный, әмма барыбер киләчәккә өметлерәк карыйлар. Үзәк банк, мәсәлән, бәяләр төшүен – дефляцияне көтә. Моны булдырмас өчен төп ставканы киметергә җыена. Чираттагы утырышта ук процент ставкасы янә кимер дип көтелә. Кредитлар арзанрак булачак, депозитларга азрак түләячәкләр. Халык яңадан кредит алып, куллануны арттырсын һәм икътисадны инфляция рельсларына күчерсен дигән сәясәт өстенлек ала.

Чит ил компанияләренең безне ташлап китүе дә җитештерүне киметер дип курка пессимист аналитиклар. Ләкин аларга алмашка «дус ил»ләр бизнесы ашкына. «Москвич» заводы Кытай автомобильләре модельләрен үзенең киләчәк продукциясе итеп тәкъдим итеп тә өлгермәде, җитештерү мәйданына фарсылар дәгъва итә башлады. Иран белән якынча килешү төзелгән икән инде. Россиядәге «Иранлылар чит илләрдә» дигән үзәк җитәкчесе Мирзаи Гази үз иле бизнесының «Москвич» бренды белән автомобильләр җитештерү нияте зур булуын әйтә. «Бездә – технологияләр, Россиядә җитештерү куәтләре бар. Шуңа күрә без тырышлыкларны берләштереп, Көнбатыштан бәйсез рәвештә автомобильләр җитештерә алабыз», – ди ул. Фарсылар Чаллы һәм Алабуга шәһәрләрендә дә «Волга» һәм «Победа» брендлары белән үз автомобильләрен чыгарырга телиләр. Шундый ук ният Кытайда да бар. Кайсы өстенлек алыр, әлегә мәгълүм түгел.

ДӨНЬЯНЫ ЯҢАЧА ҮЛЧӘРГӘ ӨЙРӘНӘБЕЗ

Сабак

15–17 августта Казан федераль университетының Алабуга институты базасында XII халыкара мәктәп укытучылары фестивале узачак. Анда катнашучы иң актив мөгаллимнәр шифаханәгә юллама белән бүләкләнәчәк. Быел фестивальгә килүчеләрне ниләр көтә?

mon.tatarstan.ru

«Татар-информ»да фестиваль уңаеннан уздырылган матбугат очрашуында Алабуга институты директоры Елена Мирзон билгеләп үткәнчә, шушы еллар эчендә төрле төбәкләрдән барлыгы 10 меңләп укытучы катнашкан. Быел әлегә 1200ләп педагогтан гариза кергән. Алар арасында Үзбәкстан, Кыргызстан һәм Беларусь укытучылары да бар. Фестивальдә катнашу өчен взнос кертергә кирәк. Анда онлайн да катнашырга мөмкин. Гаризаларны 1 августка кадәр кабул итәләр. Фестивальдә актив чыгыш ясаучыларга киләсе елда бушлай катнашу мөмкинлеге бирелә.

– Август киңәшмәләрендә күбрәк мәгариф түрәләре катнаша, укытучылар бу аралашудан читтә кала иде. Шуңа күрә 12 ел элек без алар өчен үзебездә фикер алышу мәйданчыгы булдырдык. Фестивальдә Сахалиннан башлап Калининградка кадәр мөгаллимнәр катнаша. Чарада көн кадагында булган төрле темалар күтәрелә. «Түгәрәк өстәл»ләр, тематик бәйгеләр, мәктәп музейлары семинары, төрле мастер-класслар көтә. Беренче бүлектә бүгенге вазгыятькә кагылышлы политинформация сәгатьләре урын алачак. Укытучылар илдә ниләр барганын белеп торырга тиеш, – диде Елена Мирзон.

Татарстан Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр буенча комитет рәисе урынбасары Людмила Рыбакова быел беренче мәртәбә оештырылачак «Ачык аралашу» мәйданчыгы турында сөйләп үтте.

– Фестивальләрнең берсендә академик Александр Асмолов: «Яңа дөньяны үлчәү өчен иске картаны кулланырга ярамый», – дигән иде. Шуны истә тотып, быел ачык студия булдырдык. Соңгы вакытта федераль законнарга күп кенә үзгәрешләр кертелде. Мәсәлән, быел «Мәгариф турында»гы РФ Законында, «хезмәт күрсәтү» дигән төшенчә бетерелеп, «мәгариф программалары» дип үзгәртелде. Бу укытучыларның дәрәҗәсен күтәрә, – ди Людмила Рыбакова.

Шулай ук ул озайтылган көн төркеменә кагылган закон проектына да тукталды. Моңа кадәр анда аңлашылмаучанлыклар күп иде. Дәрестән соң кайбер төбәкләрдә өй эшен эшләтсәләр, икенчеләрендә бөтенләй бирмәделәр. Хәзер «продленка»ны оештыру тәртибе үзгәртелеп, уку һәм күңел ачу чараларына бердәм таләпләр куелачак. Ниһаять, укытучылар документны да азрак тотыра башлаячак.

– Туксанынчы еллар башында укытучы бары уку, тәрбия планын язса, укучыларның өлгереш тәртибен алып барса, хәзер ниләр генә тутырмыйлар. Хисап эше күп дип, эштән китүчеләр дә бар. Кәгазь эшен киметү буенча сөйләшүләр күп булды. Хәзер укытучыларга Мәгариф министрлыгы тәкъдим иткән документларны гына тутырырга туры киләчәк. Фестиваль кысасында бу хакта да фикер алышулар булачак, – ди Людмила Рыбакова.

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының гомуми белем бирү һәм йомгаклау аттестациясе бүлеге башлыгы Татьяна Алексеева уку сыйфатын яхшырту буенча башкарылган эшләр белән таныштырды. Соңгы дүрт ел эчендә республикада 400ләп мәгариф объекты булдырылган. «Үсеш ноктасы» проекты буенча 253 авыл мәктәбендә фән кабинетлары җиһазландырылган. Быел тагын 117се ачылачак. Баштарак ОБЖ, технология кабинетлары яңартылса, шахмат зоналары булдырылса, соңгы елларда физика, химия, биология кабинетлары заманча җиһазлар белән баетыла. Болар белем сыйфатын яхшыртуга ярдәм итә, авыл мәктәбен үзгәртәчәк, дип өметләнә белгеч.

Татьяна Алексеева әйтүенчә, фестивальдә функциональ грамотага өйрәтү хакында да сөйләшәчәкләр. Киләсе елдан кертеләчәк яңа белем бирү федераль стандартларында да моңа зур игътибар бирелә.

– Укучылар алган белемне тормышта да куллана белергә тиеш. Быел без апрель аенда халыкара тикшеренүләрдә катнашырга тиеш идек, тик геосәяси вазгыять сәбәпле, бу эш барып чыкмады. PISA тикшеренүләреннән китәчәкбез, аның урынына илдә белем сыйфатын бәяләүнең яңа формасы булдырылачак, – диде Татьяна Алексеева.

Сәрия МИФТАХОВА

ИЛ САКЧЫСЫ

Әгерҗе егете Сергей Гугало Украина хәрби көчләре танкын, ике БМП, пехота позицияләрен һәм 20 националистны юк иткән. Батыр турында аны якыннан белгән кешеләр белән сөйләштек.

Россия солдатлары Украинада махсус хәрби операция барышында батырлык, хәрби осталык һәм үз бурычына тугрылык үрнәкләрен күрсәтә. Шуларның берсе – Әгерҗе егете, 22 яшьлек Сергей Гугало. Аның батырлыгы хакында Россия Оборона министрлыгы хәбәр итте.

Россия хәрбиләренең батальон-тактик төркеме (аның составында танк взводы төзәүче-операторы ефрейтор Сергей Гугало да була) бер торак пунктны азат итү өчен сан ягыннан күпкә өстен дошман белән аяусыз сугыш алып бара. Украина боевикларының танк ротасы пехота ярдәмендә, уңайлы урынга урнашып, торак пунктны саклый. Ефрейтор Гугало танк экипажы белән кинәт кенә бөтенләй көтелмәгән яктан дошманның танк ротасына һөҗүм итә. Ул бер танк, ике БМП машинасы һәм 20 кешене юкка чыгара. Шулай итеп, Россия хәрбиләре, ефрейтор Сергей Гугало батырлыгы ярдәмендә торак пунктны тулысынча азат итүгә ирешә.

Сергей белем алган Әгерҗенең 2 нче номерлы мәктәбе директоры Оксана Горось егетне, мәктәптә укыган чакта ук үз гамәлләренә тиешле бәя бирә белде, дип мактады.

– Барлык укытучылар да Сергейны бары яхшы яктан гына искә ала. Гап-гади, бик тырыш гаиләдән ул. Әти-әнисе биргән тәрбиясе аны күпләр өчен үрнәк итте. Кечкенә сыйныфларда укыганда ук җаваплылыгы, үз гамәлләренә тиешле бәя бирә белүе белән башкалардан аерылып торды. Спорт белән бик дус иде – хоккей уйнады. Аның батырлыгы турында ишеткәч, бик горурландык. Якшәмбе көнне укытучылар белән бергәләп каршы алдык үзен. Аны үзе укыган мәктәпкә чакырып, очрашулар уздырырга ниятлибез, – дип сөйләде ул.

Армиягә киткәнче Сергей Түбән Кама агросәнәгать көллиятенең Әгерҗе филиалында белем алган. Уку йортының директоры Илшат Гайнетдинов егетнең ихтыяр көченә электән соклануын яшермәде.

– Бала чагыннан ук хоккей уйнады ул. Гаять ышанычлы сакчы булды. Кечкенә чакта ук спортта да, тормышта да холкы чын сакчыларныкы кебек иде. Дуслары өчен җанын ярып бирергә әзер егет ул. Тимер юлда эшли торган әтисенең һөнәрен дәвам итеп, безнең көллияттә машинист белемен алды һәм укуын кызыл диплом белән тәмамлады. Эшкә урнашырга өлгермәсә дә, укыган чакта ук үзен чын профессионал итеп күрсәтте. Бик борчылдык Сергей өчен, ләкин үзен чын батырларча күрсәтәчәгенә һич шикләнмәдек. Без аның белән горурланабыз. Әлбәттә, мондый егетләр турында яшьләр белеп торырга тиеш. Без дә мондый мөмкинлекне кулдан ычкындырмаячакбыз, – дип сөйләде ул.

МАРАТ ТӘРӘЗӘЛӘРЕ

Авыл эшмәкәрләре

Моны нәрсә белән тутырырбыз?! Мең квадрат метрлы бинада эш башлаганда әтиле-уллы Галимҗановлар шулай дигән була. Әмма җитми дә әле, еллар үткәч, янкорма өстәргә туры килә. Заманча тәрәзә-ишекләр җитештерү белән шөгыльләнә алар. Балтач районының Кече Лызи авылында урнашкан ширкәтләренә ун ел икән инде.

– Икебезнең уртак бизнес итеп башладык, исемне дә Фәрит һәм Марат исемнәрен берләштереп, «ФарМат» дип куйдык. Уртак бизнес дисәк тә, соңгы елларда «дилбегә» Маратта инде, – ди Фәрит. – Мин булышам гына.

Фәрит – безнең буын райондашлар өчен бик билгеле кеше. Районда «Факел» спорт-яшьләр клубын оештырган кеше. Янына үзе кебек фанат тренерлар туплап, күпкатлы йортның подвалында йөзләп яшүсмер белән төрле түгәрәкләр алып бардылар. Уңышлары да күп булды. Гаилә корып, уллары тугач, үз эшен булдырырга карар кыла тәвәккәл егет. Кечкенә генә гаражында агач рамнар, тәрәзәләр һәм башка әйберләр ясый башлый. Кулыннан эш килә, заказлар арта, ярдәмчеләр дә алырга туры килә. Марат мәктәпне тәмамлаганчы шулай эшлиләр.

Башка урыннарда аз гына эшләп ала да Марат: «Әти, хәзер агач рамнар вакыты үтеп бара, әйдә, без дә пластик тәрәзәләр эшли башлыйк», – ди. Әти кеше риза булса да, районда инде бу эш белән шөгыльләнүчеләр бар, күп булса, берничә елга гына җитәрлек эш булыр инде дип шикләнә. Тик улына каршы килми. Үз эшен башлаучыларга бирелә торган 50 мең сум акчаны ала да, Марат шәхси эшмәкәр булып эшли башлый. Бөтенесен интернеттан өйрәнә. Укып өйрәнә дә, остаханәгә чыгып, бер өлешен эшләп карый, аннан – икенче өлешен. Әнә шулай итеп, иң элек барысына да үзе өйрәнә. Әтисендә агач рамнар эшләгән егетләр Маратка күчә. Эшләп киткән чакларын Марат бүген күңелле итеп искә ала:

– Җиһазларны интернет аша таптым, Чиләбе өлкәсендәге бер белмәгән кешегә 100 мең сум акча күчердек. Гади генә, кулдан эшләнгән станоклар иде алар. Шактый озакка сузылса да, барыбер килделәр бит! Берничә ел шулар белән эшләдек...

Бер ел әнә шул гаражларындагы остаханәдә эшлиләр. Заказлар арта, яңа линияләр, киңәю кирәк була. Киңәергә кирәклеген аңлаган Галимҗановлар ул чактагы район җитәкчеләреннән элекке СМУ территориясендә тик торган гараж бинасын сорый. Тик соңга калган булып чыгалар, аны инде башка кешегә вәгъдә иткәннәр икән.

Кече Лызидагы иске мәктәп бинасын тәкъдим итәләр. «Бардык. Карадык. Ярым авария хәлендәге 1000 квадрат метрлы бина. Безгә бер дә ошамады ул. Икенчедән, Кече Лызи безгә бөтенләй чит җир кебек тоелды», – дип искә ала ул көннәрне Марат. Әмма башка вариантлары да, сайланырга мөмкинлекләре дә булмый.

– Монда керсәк, улым, безгә акчаны кая куярга икән дигән сорау булмаячак, – ди әти кеше. Алгарак китеп булса да, әйтим, бүген бу бина да, Кече Лызи да алар өчен чит-ят җир түгел. Кешеләр бик әйбәт бу авылда, шөкер, ун елга якын эшләп, бер аңлашылмаучанлык булганы юк, диләр...

Башта бинаның яртысын ремонтлыйлар. Акрынлап эшкә керешәләр: бередә пластик тәрәзәләр генә түгел, агачтан җиһазлар – урындык, өстәл, караватлар да ясый башлыйлар. Җиһазлары да бик әйбәт сатыла, бүгенгә кадәр сорап киләләр. Тик биш ел элек җиһаз ясауны туктата Галимҗановлар һәм бинаның шул өлешендә тормышта кирәкле барлык товарларны табып булырлык итеп кибет ачалар. Бу як халкы өчен бигрәк тә шәп булган ул. Әле Балтачтан, күрше Арча районыннан да киләләр икән.

Икенче төп цехта эшләнүче пластик тәрәзә-ишекләрнең дә ниндие генә юк. Металл конструкцияләрне заказчылар таләбе буенча үзгәртеп кенә торалар. Төсле пластиклар да, караңгылатылган пыялалар да, төрле формадагы тәрәзәләр, ишекләр, җылытылган веранда (пластик конструкция белән җыйналган) да эшлиләр. Моңа кадәр гади кешеләр белән генә түгел, хуҗалыклар белән дә уңышлы эшләгәннәр. Хәзер бит нинди генә төзелеш булса да, тәрәзәләре пластиктан эшләнә. Фермаларда да. Ясап кына түгел, илтеп урнаштырып та бирәләр. Шул ягы да уңайлы.

Килгәч тә, бигрәк зур бина, моны нәрсә белән тутырырбыз, дигән Галимҗановлар бүген аның бер өлешенә янкорма да өстәгән. Ул өлешендә өстәмә тагын берәр продукция җитештерергә ниятлиләр. Әнә шулай ун ел буе бертуктамый төзи, ремонтлый да алар. Әмма зарланмыйлар, бу бинаны тәртипкә китерүгә киткән акчаны санамыйбыз, дип шаярталар.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

МИН БЕЛГӘН КУРАМША

Шәхесләребез

Рамилгә «Курамша» дип кем дәшкәндер – белмим, әмма татар эстрадасының мәшһүр сүз остасы Фәйзи ага Юсуповның гөлдерәп торган тавыш белән «Курамша» дип әйтүе күңелгә кереп калган. Фәйзи аганы еш кына «Татар сүз сәнгате генералы» дип атыйлар иде, ә Рамил хакында ниләр әйтеп булыр икән? Мәсәлән, «виртуоз баянчы» дисәң, бу Курамша иҗатының бер читен ачып карау кебек кенә тоелыр иде.

Күпләр аңа Илһам Шакировның баянчысы буларак бәя бирәләр. Бу, бер уйлаганда, дөрес тә. Татар җыры легендасы белән 20 ел буе бер сәхнәдә яшә әле син! Минем Илһам ага концертларын сәхнәләрдә караганым бар һәм һәрвакыт Рамилнең уйнавына игътибар итә идем. Җырчыны тыңлый белү – үзе зур талант билгесе. Баянчы – аккомпаниаторның, ягъни Курамшаның көйгә ритм һәм гармония биреп баруына, бизәкләр өсти белүенә соклана идем мин.

Аккомпанемент – француз сүзе, «озатып бару» дигәнне аңлата. Заманында барабан, бубен һәм шуның ише башка бәрмә уен кораллары төп мелодиягә ритм биреп, башкаручыны озатып барган. Безнең беренче баянчыларыбыз да, көйгә бик сак карап, җырчыга ияреп кенә бардылар, ә Курамша – башка «камырдан ясалган» егет. Ул – чын мәгънәсендә иҗат кешесе, җыр белән, җырчының рухи халәте белән яши.

Бер кызык хәл искә төште әле. Рамилнең баянчы булырга теләгәнен белгәч, бабасы Курамша: «Тапкансың эш, баянчы кәсепмени ул?» – дип әйткән булган. Инде соңрак, оныгы Казанга килеп, музыка училищесында укыганда ук, радио аша көйләр яңгырата башлагач, баянчы дигән һөнәр барына ышанган һәм оныгына үзе хәер-фатыйха биргән ди. Рамил бу хакта бүген көлә-көлә сөйли. Аның елмаюлы йөзен күргәч, күңел шатлана. Каты авырудан соң өйдәге караваттан ерак китә алмаган егетнең рухы көчле булуы сокландыра мине. Шөкер, үз акылында, хәтере әйбәт аның.

Хәтер димәктән, Рамилнең телевидение аша «сольный» чыгыш ясавы искә төште әле. Минем телевидениедә музыкаль редакция мөхәррире булып эшләгән чак. Рамил белән әледән-әле очрашкалап-сөйләшкәләп тора идек. Берсендә бу: «Кордаш, радиода баян өчен үзем эшкәрткән көйләрнең язмалары шактыйга җыелды, телевидение өчен берәр кечкенә генә тапшыру әзерләмибезме?» – диде. Ул заманда бер баянчы турында гына тапшыруларның булганы юк иде. «Ярый, эшләрбез», – дидем дә, Курамша белән бергә программа төзедек. Аны сценарий рәвешенә китереп яздым да, ул чакта нәфис тапшырулар редакциясен җитәкләгән Әминә Сафиуллинага бирдем. Башта Әминә апа гаҗәпләнеп куйды. «Бер баянчы турында гына тапшыру эшләп булырмы соң, тагын бер баянчы кушмыйбызмы?» – ди. Рамил үзе әллә ничә баянчыга тора, дигәч, үзең беләсеңдер инде, дип ризалашты. Акыллы, зирәк кеше иде Әминә апа. Аның «җиңел кулы» белән дигәндәй, без әле тагын берничә баянчы турында тапшырулар әзерләдек. Әмма мондый тапшырулар озакка бара алмады, чөнки баян өчен халык көйләрен эшкәртүчеләр, баян өчен пьеса язучылар һәм аларны үзләре үк башкаручылар санаулы гына булып чыкты.

Аның каравы Курамша, баян һәм оркестр өчен концертино язып, аны Анатолий Шутиков җитәкләгән халык уен кораллары оркестры белән әзерләп, янә телевидениегә тәкъдим итте. Без аның видеоязмасын башта үзебездә күрсәттек, аннан Мәскәүгә – Үзәк телевидениегә җибәрдек. Курамшаның оркестр белән үз әсәрен башкаруы күпләр өчен көтелмәгән хәл булды. Кызып китеп дигәндәй, без Мәскәүгә Рамилнең «сольный» концертын да җибәргән идек, аңа СССР дигән зур илнең мәшһүр музыкантлары игътибар иткән. Ленинград консерватория профессоры, танылган баянчы Олег Шаров Курамшаның «Җәйге авыл урамында» дигән әсәрен үзенең концерт программасына керткән һәм афишасын фотога төшереп, Рамилгә җибәргән. Моны миңа Курамшаның дусты, баянчы Хәйдәр Сафин сөйләгән иде. «Күз алдыңа китер: Риман, афишада Бетховен, Чайковский, Бах белән бергә Рамилнең дә фамилиясе торсын әле!» – дигән иде ул.

Курамша – артык тыйнак егет. Аның турында шактый нәрсәне башкалардан ишетеп беләсең. Халкыбызның Рамил баян өчен эшкәрткән «Әпипә» бию көен заманында «Урал триосы» (Иван Шепельский, Анатолий Хижняк, Николай Худяков) башкарган булган. «Өчлек» баянчылары Курамша чыгышын караганнар да аның иҗаты белән кызыксына башлаганнар. Үз репертуарларына кертергә ниятләгәч, Рамилдән: «Әпипә» ни дигән сүз соң ул, нәрсәне аңлата?» – дип сораганнар. Аптырап тормаган Курамша: «У вас – «Барыня», у нас – «Әпипә», – дип җавап биргән ди. Янәсе, шуннан үзегез аңлагыз. Мин монысын да Хәйдәр Сафиннан ишеттем. Хәйдәр әле: «Рамилнең баян өчен язылган, эшкәртелгән әсәрләрен халыкара конкурслар лауреатларының җидесе башкарганын беләсеңме?» – дип тә өстәп куйган иде. «Син әйткәч, белдем инде», – мәйтәм. Хәйдәр Курамша иҗаты турында шактый күп мәгълүмат бирде миңа.

Аның әсәрләрен баянчы-виртуоз, композитор, Россиянең халык артисты Виктор Гридин башкаруын да әйтте.

Кызганыч, Виктор Федорович 1997 елда вафат булды. Русларның гына түгел, Россиядә яшәүче башка халык вәкилләренең иҗатына да бик игътибарлы шәхес иде ул. Андыйлар күп түгел шул хәзер. Халык иҗатына мөкиббән киткәннәр үзбезнең татарда да юк дәрәҗәсендә.

Ярый әле Арчада ике елга бер Рамил Курамшин исемендәге баянчылар конкурсы уза. Курамша анда үзе жюри рәисе дә иде. Хәзер жюрины халыкара конкурслар лауреаты Айдар Вәлиев җитәкли. Ярый әле «изге урын»ны буш тотмый торган шундый егетләребез бар. Әмма, ни генә дисәң дә, Курамша Курамша булып кала инде. Аның, бер караганда, музыкантныкына охшамаган кыска, юантыграк бармакларыннан барлык бормалары, гүзәллеге белән татар моңы сибелә һәм күңелгә кереп утыра. Курамшаның уйнавын беркемнеке белән дә бутап булмый, нәкъ Илһам абыйның тавышын бутап булмаган кебек. Аның баянда уйнау буенча язган кулланма дәреслекләрен музыка мәктәпләрендә, музыка училищеларында, консерваториядә кулланалар. Ходай бер бирсә бирә бит ул: Курамша – композитор да. Үзенең җырларын үзе башкаручы да. Тарихи хәтерне саклау өчен «Чордашларым – моңдашларым» дигән китап та чыгарды. Исеменнән аңлашылганча, ул татарда милли моң саклансын өчен язылган кебек. Курамша журналист та: «Ватаным Татарстан», «Мәдәни җомга» һәм башка кайбер басмаларда күренекле шәхесләребез турында күпме язмалары чыкты аның.

16 июльдә Татарстанның халык артисты Рамил Курамшинга 75 яшь тулды. Егет кешегә күп түгел әле бу. Курамшаны Ходай яман зәхмәтләрдән генә сакласын! Ә без – «ВТ»лылар баянчы, композитор, җырчы, гомумән, татарның асыл егетен туган көне белән котлап, иң изге теләкләребезне юллыйбыз.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Югалту

Елмаеп кайтып керер кебек

Зөлфия, Заримә, Гайни, Ландыш, Айшә, Сәкинә... Камал театрының бер почмагында шыпырт кына аның рольләрен барлыйлар. Кояш, диләр, игътибарлы, диләр. Аннан уңайсызланып кына «иде» дип өстәп куялар. Нишлисең, Татарстанның халык артисты Раушания Юкачева турында да үткән заманда сөйләшергә калды. Якты актриса 63 яшендә мәңгелеккә китеп барды.

«Миндәге көчне роль белән генә чыгарып бетереп булмый, шуңа күрә гомер буе ике эштә эшләдем», – дигән иде ул соңгы әңгәмәсендә. Төрле елларда Камал театры директоры урынбасары да, шәһәр филармониясе директоры да, «Балачак» студиясе җитәкчесе дә була ул. Әмма бу эшләр бервакытта да иҗатка хилафлык китермәгән. Театр исә гаиләгә дигән игътибарны урламаган.

Татарстанның халык артисты, скрипкачы Фоат Әбүбәкеров исә боларга өстәп, аның янәшәсендә булганнарга кайгыртучан булуы турында сөйләде:

– Без аның белән дуслар идек. Дача йортларыбыз да кара-каршы иде бит. Раушаниянең иң асыл сыйфаты – кешелекле булуы. Ул һәрвакыт кемнедер кайгыртып яшәде. Ире Николай исән вакытта аны кайгыртты, аңа иҗади яктан ачылырга бөтен мөмкинлекләрне тудырырга тырышты. Коляның кинәт китеп баруын бик авыр кичерде. Аның белән төннәр буе сөйләшеп, елап утыра идек. Ул чорда егетләребез бер-бер артлы дигәндәй китеп бардылар бит: Шамил, Коля, Мансур, Габделфәрт... Инде менә Раушанияне озатабыз. Көчле актриса, булдыклы, бөтен яктан килгән, мин дип күкрәк киереп йөрерлеге бар иде. Ә ул бервакытта да, мин – актриса, дип борын чөермәде, беркемнән дә көнләшмәде, беркем белән дә конфликтка кермәде. Ул беренче чиратта кеше иде. Соңгы көннәргәчә сәхнәдә булды. «Гөргөри кияүләре»ндә бик яратып уйный иде инде, ә менә 24 июньдә сәхнәгә чыга алмады, авырып китте. Ул чакта беребез дә хәле мөшкел дип уйламадык. Шул килеш ялга таралдык. Хәер, Раушания театрга хилафлык китерә торган кешемени соң инде ул? Үз хәле турында беркемгә бер сүз ләм-мим. Раушаниячә инде.

Татарстанның халык артисты Әсхәт Хисмәт исә аның Тәмлетамак апага әверелүен искә алды:

– Күп еллар бергә эшләдек. Иң беренче «Ләйсән ире Хәсән» (Юныс Сафиуллин) спектаклендә бергә уйнадык. Аннары – «Яшь йөрәкләр»дә (Фәтхи Бурнаш), соңрак «Мәхәббәт турында сөйләшик» (Илгиз Зәйни) спектаклендә ир белән хатын булдык... Раушания «Балачак» студиясен җитәкләгән чорда бик матур образлар тудырдык. Нәтиҗәдә беребезне – Тәмлетамак апа, икенчебезне Акбай абый дип йөртә башладылар. Туфан абыйның алты серияле «Авыл эте Акбай» безне балаларның иң якын дустына әверелдерде. Ә «Зәңгәр шәл»дә ул минем биш хатынның иң усалын уйнады. Инде шуларны уйлап, юаныргы гына калды. Нишләтәсең бит, киләбез дә китәбез. Аллаһы Тәгалә шулай язган. Сагынырбыз, юксынырбыз Раушаниябезне... Бу ай безнең өчен нишләптер югалтулар ае ул. Фирдәвес Хәйруллина шушы айда киткән иде, Хәлим Җәләй, Әнвәр Гобәйдуллин...

Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Илдар Хәйруллин хушлашу мәрасимен алып барды. Ул Раушания Юкачеваның иң асыл сыйфатларын телгә алды:

– Аларны Коля белән икесен Марсель Сәлимҗанов Камал театрына кабул итте һәм ялгышмады. Аңарчы бу пар Әлмәт театрында эшләп ала. Раушания үзенчәлекле, кабатланмас артист иде. Булдыклы җитәкче буларак та үзен танытты. Аның тырышлыгы белән туксанынчы елларда, иң катлаулы вакытта «Балачак» студиясе оешты. Театрны танытуда бу студиянең дә роле зур булды. Алар Коля белән бик матур гаилә кордылар. Аны югалту Раушаниягә зур тетрәнү булды. Раушания шул вакытта егет икәнлеген күрсәтте. Бәлкем ялгызы калганда сыгылыплар төшкәндер, әмма эшкә ул елмаеп килеп керә, янып эшли, һәрвакыт нинди дә идеяләр уйлап таба иде.

Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Наилә Гәрәева бу хәбәргә әле һаман ышанып бетә алмавын сөйләде. Әле генә бергә ял итә алар һәм кинәт аңа үлем хәбәрен җиткерәләр:

– Мин бу хәбәргә берничек тә ышана алмыйм. Соңгы ун көндә бергәләп шифаханәдә ял иттек. Шундый күңелле көннәр булды ул. Икәү ял иткәндә дә Раушания гел минем өчен борчылып яшәде. Даруыңны эчтеңме, суыңны эчтеңме, әйдә урманда йөреп кайтабыз дип, әйдәкләп торды. Театрда да миңа мөгамәләсе шулай иде. Ул – мәрхәмәтле, көчле рухлы кеше. Аның таланты халык мәхәббәтен бик тиз яулап алды. Әле шифаханәдә дәваланганда «Мәхәббәт турында сөйләшик» спектакленең телевизион версиясен карадык. Үзенең уйнавын соңгы каравы булган икән. Хәзер менә туган авылына ахирәт йортына озатабыз. Минем өчен ул бераздан елмаеп кайтып керер кебек.

Раушания Хөснетдин кызы Юкачева туган авылы – Питрәч районы Күн авылы зиратында җирләнде. Искә алуыбыз рухына дога булып барсын, гүрен нурлы итсен.

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры коллективы Татарстанның халык артисткасы

Раушания Хөснетдин кызы ЮКАЧЕВАның

вафат булуы турында хәбәр итә һәм мәрхүмәнең туганнары, дуслары, якыннарының авыр кайгысын уртаклаша. Татар театрының талантлы артисткасы, сәнгатькә тугрылыклы булган дустыбыз, сәхнәдәшебезнең якты истәлеге безнең күңелләрдә мәңге сакланыр.

РӘССАМ ГАРРИ ШАХНАЗАРОВ:

«ӨЙДӘ ЯСАУ ЭШ ТҮГЕЛ»

Тәтештә яшәүче Гарри Шахназаровның гараж ишегенең төшкә кадәр беркайчан да ябылып торганы юк. Шундагы остаханәсендә көн саен 3–4 сәгать иҗат итә ул. «Комачауламагыз!» дигән язу да элеп куйган. Мәктәп урамыннан үтеп-сүтеп йөрүчеләр арасында төрле сорау бирүчеләр дә бар. Күзәткәнгә сүз әйтми, тик бүлдергәнне яратмый. Җиденче ел инде рәссамның картиналары әнә шулай урамда туа.



Илдар Мөхәммәтҗанов

Гарри Шахназаров Кавказ якларында туган. Тик әрмән егетенең яшьлек еллары Бакуда үткән. Шуңа күрә ул азәрбайҗан телен туган теленә караганда да яхшырак белә. Рәсемне исә 5–6 яшьлек чагыннан ук ясый башлаган. Әти-әнисе аңа төсле карандаш, буяу, альбомнарны беркайчан да кызганмаган. «Һәр диварда келәм эленеп тора, караватыма да түшәлгән ул. Мине хәтта көйләргә дә кирәкми иде. Шушы әкият дөньясында изрәп йокыга китә идем. Бизәкләрен кәгазьгә төшерәм. Келәмнәрдәге матурлык иҗатыма йогынты ясаган, димәк, – ди 66 яшьлек Гарри, бала чагын искә төшереп. – Диңгез янәшәсендә яшәгәнгәме, ярсу дулкыннарны ясарга ярата идем. Әти миннән бөек рәссам чыгар дип хыялланды. Юк, андый үрләргә күтәрелә алмадым, әмма миннән ихлас рәссам килеп чыкты. Барлык картиналарны күңел аша үткәреп иҗат итәм.

Мәктәпне тәмамлагач, Гарри абыйсы киңәшен истә тотып, Чиләбе өлкәсендәге авиация училищесына юл тоткан. Тик анда җиде ай гына укыган. «Авиатехник булырга хыяллансам да, математика белән дуслашып китеп булмады. «2ле»ләр алгаладым. Нишләтәсең, интеграл, дифференциаллар башыма сыймады. Беренче елны бик тырышырга, түзәргә туры килде. Аннан армиягә киттем», – ди ул, яшьлегенә кайтып.

Бакуда яшәгәндә Россиягә килеп, төзелештә акча эшләгән. Булачак хатыны Раиса белән Мәскәүдә танышканнар. Гаилә коргач, тормыш иптәшенең туган ягы Тәтешкә күченеп кайтканнар. Моның өчен Гарри бер дә үкенми. Үзенә шөгыль тапкан. Машина сатып алып, таксист булып хезмәт иткән.

Бер-берсен гомер буе яратып яшәгән парның әле дә хисләре сүнмәгән. Раисаның сәламәтлеге какшау да комачауламаган. Менә инде ничә елдан бирле рәсем ясап кына калмый, үзе ашарга пешерә, өй җыештыра, хатынын тәрбияли.

– Өйдә ис чыгарып, рәсем ясау эш түгел. Беренчедән, хатынымны уйлыйм. Саф һавада ясыйм. Хатыным сәнгатьне ярата. Тәрәзәдән карап, миңа илһам биреп, мактап тора, – ди Гарри Шахназаров.

Тыштан җитди кебек күренсә дә, күңеле нечкә рәссамның. Ишектәге «Комачауламагыз!» дигән язуны да әллә кемләнеп элеп куймаган. «Карасыннар, тик игътибарымны гына читкә юнәлтмәсеннәр. Сәлам бирүчеләр белән исәнләшәм дә эшемне дәвам итәм. Рәсем ясау күңелемне тынычландыра», – ди әңгәмәдәшем. Кичкә калса, черкиләр комачаулый башлый. Шуңа күрә рәсемне көндез ясау аның өчен күпкә яхшырак.

Тәтештә рәссамнар тагын бар, әмма гаражда ясаучысы ул гына. Гарри Шахназаров кешенең кәефен күтәрә торган җете төсләрне кулланырга тырыша. Гараж төбенә җыелучыларны да ул нәкъ менә шушы шатлык төсләре тартып китерәдер дип уйлый. Аның иҗатында табигать күренешләре, айлы кичләр, Идел елгасы, Вшиха, Кавказ таулары чагылыш тапкан. Вшиха тавы – Тәтешнең бик матур урыны. Шунда барып та иҗат итә икән. Бигрәк тә таң атканны, кояш баеганны сурәтләргә ярата. Әлеге дә баягы төсләр балкышы җәлеп итә аны. Иң яраткан төсе – зәңгәр. Монысы инде диңгезгә гашыйк булган малайның күңеленә сеңеп калган төс. Образларын төштә дә күргәли, тик андый очраклар сирәк. Гадәттә, кызыклы фильмнар, әкиятләр карагач, яңа идеяләр туа икән. «Кешенең хезмәтен кабатларга яратмый. Идеяләр – башта. Миңа пумала тотып иҗат итәргә генә кала, буяулар гына җитсен. Бер картинаны ясар өчен 3 көн кирәк», – ди ул.

Иҗат эшләрен 600–1000 сумга тәкъдим итә. Сораучылар бар. Интернетны белми, шуңа күрә заказны күбрәк танышлары аша кабул итә.

Хыялы – тарихи темалар иҗат итү. Әнә бит Вшиха тавы тарихын ничек оста итеп сөйли. Безне дә шунда алып барып күрсәтергә риза хәтта. «Болгар ханлыгын ясар идем, тик чыгымнар күп сорый. Зур картина өчен бөтенләй икенче формат һәм буяулар кирәк. Биш төрле буяу белән генә тарихны җитди итеп чагылдырып булмый», – ди рәссам.

Сәрия МИФТАХОВА

Спорт

Бергә кайтабыз!

Яңа сезонны әнә шундый ният белән башлаган «Рубин» беренче лигадагы тәүге очрашуында үз кырында Мәскәүнең «Родина» командасын отты. 2:0 исәбе белән тәмамланган матчта ике тупны да яңа уенчы Джоэль Фамейе кертте.

«Барселона», «Интер», «Ливерпуль» һәм башкаларны карап кинәнгән Казан тамашачысы быел Россия футболындагы чынбарлыкны күрәчәк. 20 елдан соң «Рубин» кабат беренче лигада чыгыш ясый. Монда безнекеләргә Калининград һәм Хабаровскига сәяхәт кылырга, дөнья чемпионатының ни икәнен белмәгән стадионнарда чыгыш ясарга, иң мөһиме, яңа уенчылардан команда тупларга һәм җанатарларда ышаныч уятырга туры киләчәк.

Премьер-лигадан төшеп калуга ук Казанда кабат иң көчлеләр сафына әйләнеп кайту турында хыяллана башладылар. Май ахырында яңа команда җыела башлады. Танылган исемнәрдән бигрәк, ышанычлы һәм беренче лиганың ни икәнен яхшы чамалаган уенчыларга өстенлек бирелде. Биредә тупка тибү генә җитми, көрәшергә кирәк. Джоэль Фамейе узган ел беренче лигада иң кыйммәтле һәм нәтиҗәле уенчыларның берсе булып танылды. Гана футболчысына 25 яшь. Ул чыгыш ясаган «Оренбург» премьер-лигага чыкса да, Фамейе «Рубин» белән кабат беренче лигада туп кертергә тели. «Уфа»дан берьюлы өч уенчы килде. Берсе – Россия җыелма командасына да чакырылган Олег Иванов. Озак елар «Ахмат»та чыгыш ясады. Икенчесе – Дмитрий Кабутов. Әле узган атнада гына Уфадан Казанга капкачы Александр Беленов килеп кушылды. «Ростов»тан арендага Александр Саплиновны алдылар. Озак еллар «Краснодар»да уйнаган тәҗрибәле Александр Мартынович та Казанга килергә ризалык бирде. Беренче лигада иң көчле уенчылардан саналган Александр Зотов («Енисей»), Валерий Чуперка («Кубань»), Артем Попов («Балтика») та «Рубин»ны премьер-лигага алып чыгарга тырышачак.

Яңа командада татар егете Камил Муллин да бар. 28 яшьлек футболчы Казанда бер уйнап киткән иде инде. «Миңа шалтыратып, уйларга бер минут вакыт бирделәр. Җавапны бер секунд эчендә бирдем. Киләсе елның маенда алтын медаль тагасым килә, – ди узган ел «Ротор»да уйнаган Камил. – Мин һәрвакыт татар егете булып калам. Тарихи Ватаныма кайттым. Клуб һәм республика өчен көрәшәчәкмен». Сүз уңаеннан, узган атна ахырында Мәскәү өлкәсенең «Химки» клубы сакчы Эльмир Нәбиуллин белән килешүне өзгәнен игълан итте. «Рубин»да тәбияләнгән егет Казанга кайтыр дип фаразлыйлар. Дөрес, башкала клубында мондый хәбәрләрне кире кагалар.

Белгечләр «Рубин»ны беренче лиганың иң көчле командасы дип атый. Яңартылган команда тәүге сынауны узган якшәмбедә тапшырды. Казан футболчылары беренче лигада беренче очрашуын уздыручы «Родина» капкасына җавапсыз ике туп кертте. Икесе дә – Джоэль Фамейеның осталыгы нәтиҗәсе. Беренчесен ул пенальти ярдәмендә кертсә, икенчесендә Казанга юкка гына чакырылмаганын күрсәтте. Иптәшләре аны планетадагы иң җитез йөгерүче Усейн Болт белән чагыштырды. Кызганыч, имгәнгән футболчы матчны тәмамлый алмады. Улбу килеп чыкса, аның урынына тупны кем кертер? Камил Муллин голлар белән еш сөендерә торган егет түгел. Премьер-лигадагы соңгы матчта Уфа капкасына пенальтидан туп кертә алмаган Виталий Лисаковичның беренче лигада уйнау теләге бик сизелми. Артем Дзюба исә Казанга күнегүләр уздыру өчен генә килгән. Баш тренер Леонид Слуцкий әйтүенчә, һөҗүмче белән килешү төзү турында бер сүз дә булмаган.

Шулай итеп, әле беренче матчтан соң ук тренерларга утырып уйланырга туры киләчәк. Очрашу да «Рубин»ның әлегә команда булып оешмаганын раслады. Бәхеткә, сезонны «Родина» белән башладылар. «Енисей» һәм «Уфа»га каршы узасы киләсе ике уенда Казан футболчыларына авыррак булачак. Әле ике атна элек кенә узган әзерлек уенында Башкортстан командасы безнекеләрне 4:1 исәбе белән тар-мар иткән иде. Ә «Родина»ны җиңгәч, «Рубин»ның баш тренеры Леонид Слуцкий тамашачыга рәхмәт әйтте. «Ак барс-Арена»га 8 меңгә якын кеше җыелды. Бер яктан, гаҗәп хәл. Премьер-лига очрашуларына бу кадәр кеше йөрмәде. Икенче яктан, футбол сөючеләргә тамаша кирәк. Премьер-лига белән чагыштырганда кайтышрак саналса да, беренче лиганың зур өстенлеге бар. Монысында Казан командасы җиңү өчен көрәшәчәк. Андый футболны исә, нинди ярыш булса да, карыйсы килә.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

	команда	очко
1	Краснодар-2	3
2	Кубань	3
3	Рубин	3
4	Арсенал Тула	3
5	Велес	3
6	КАМАЗ	3
7	Волгарь	3
8	Волна Ульяновск	1
9	Енисей	1
10	Алания	0
11	Динамо Махачкала	0
12	СКА Хабаровск	0
13	Балтика	0
14	Акрон	0
15	Нефтехимик	0
16	Родина	0
17	Шинник	0
18	Уфа	0

rubin-kazan.ru

Лилия ГЫЙМАЗОВА

АРУЛАРМЫ СЕЗ?

ПИТРАУ БӘЙРӘМЕ БЫЕЛ ДА ТАҢГА КАДӘР ДӘВАМ ИТТЕ

«Эй, без идек, без идек, менә без тагын килдек...» Мамадыш районының Җөри авылында узган Питраугa диюем. Керәшеннәрнең «җөреш»ләре бу юлы да кояш баеганчы башланып, таң атканчы дәвам итте. Шул араданиләр күреп бетергәнне хәзер сезгә дә сөйләрбез.

Бәйрәмнәрнең соңгысы

Ел саен ким дигәндә 50–60 меңләп кунак кабул итә торган Тырлау аланы турында ишеткәнегез бардыр инде. 16 июльдә дә халык шунда агылды. Татарстан районнарыннан гына түгел, Россиянең төрле төбәкләреннән килеп күңел ачтылар монда. Ә кабул итүче як – мамадышлылар, елдагыча, киң мәйданда киң күңел белән каршы алып, татар мәдәниятенең аерылгысыз өлеше булган җыру-биюләрнең иң асылын, уеннарның иң күңеллесен, кыз-түтиләрнең иң чибәрен күрсәтте.

Питрау Петр һәм Павел апостоллар хөрмәтенә уздырыла торган дини чарадан чын мәгънәсендә заманча, төрле милләт вәкилләрен бер аланга җыя торган матур бәйрәмгә әйләнде. Мамадыш районы башлыгы Анатолий Иванов шулай ди.

– Әлеге бәйрәм үсеп килүче буынга әхлакый һәм мәдәни тәрбия бирә, башка телләргә һәм мәдәниятләргә карата хөрмәт хисе уятырга ярдәм итә, милли мәсьәләләргә, тел һәм традицияләргә бәйле проблемаларга йөз тотарга өнди, алай гына да түгел, яшь, сәләтле артистлар һәм коллективлар да үзләрен күрсәтә монда. Питрау – безнең уртак бәйрәмебез. Быел да ул сезнең күңелләрдә күңелле хатирәләре белән истә калыр дип ышанам, – дип сәламләде ул.

Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Президент каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау һәм үстерү мәсьәләләре буенча комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов оештыручыларга барлык кунаклар исеменнән рәхмәт әйтте.

– Күпмилләтле Татарстанда яшәүче халыкларның милли бәйрәмнәре һәрвакыт киңлеге, матурлыгы белән шаккатыра. Бүген дә без – шундый бәйрәмнең шаһитлары. Килгән кунакларның күп булуы бик сөендерә. Һәр кеше бәйрәмнән канәгать калачагына шигем юк. Питрау – безнең уртак хәзинәбез бит ул. Без аны һичшиксез сакларга тиеш. Питрау учагының ялкыны безнең йөрәкләргә күчсен, барыбыз да сәламәт һәм бәхетле булыйк, – диде ул, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның да котлау сүзләрен җиткереп.

Милли бәйрәмнәрнең иң соңгысы да ул – Питрау. Шуңа да ял итеп, көч туплап өлгерергә киңәш итте Татарстанның керәшеннәр җәмгыяте башлыгы Иван Егоров.

– Хезмәтне һәм хезмәт кешесен данлау, табигатьне олылау безне көчлерәк итә, рухыбызны ныгыта. Питрау – республикада яшәүче халыкларның милли бәйрәмнәренең соңгысы. Ял итеп, җәйдән көч алып калыйк. Көзне тулы амбарлар һәм тыныч күңел белән каршы алырга язсын! – дип теләде ул.

Кыз кирәк тә каз кирәк

Милли бәйрәмнәрнең җырлы-биюле ачылыш тантанасы белән башланып китүенә күнегеп беттек инде. Питрауны оештыручылар, ай-яй, тырышкан – сәгать ярымлык (ә бәлки артыграк булгандыр) тамаша әзерләгән иде. Кунакларга туй «җола»сын күрсәтте алар.

Туйны бөтен кагыйдәләренә туры китереп, традицияләрен саклап алып бара торган җор телле тамадаларына кадәр бар иде. Һәм, билгеле, җырулар һәм биюләрсез дә узмады. Керәшен җыруларын беләсездер инде? Утырган җирдән биеп утырды тамашачылар да. «Туй»лары озакка сузыла башлагач кына туктадылар.

Йоласына туры китерсәләр дә, бик заманча иде туйлары. Милли ризыкларны да түтиең шәһәр урамнарында еш очрый торган «доставка» хезмәтендә эшләүчеләр кебек киенеп ташыды. Кияү һәм кәләш ягы кара-каршы басып, җырлы «баттл» оештырдылар. Керәшен җыруларын «рэп» стилендә тагын кайчан ишетер идек әле!

Туйдан сугышмыйча кайтып китмәүләрен дә белдек. Аңа кадәр көмешкәсен дә күтәреп куйдылар. Соңыннан халык алдында буш шешәләрен дә шактый озак «болгап» йөрделәр. Марат Әхмәтов әйтмешли, гайре табигый ачылыш булды ул. Бәйрәм булгач, хәлләрнең төрлесе була инде.

Тик менә шушы өлешнең озакка сузылуы бар кешегә

«Татар-информ»/Владимир Васильев

Ольга түти Питраугa әбисенең алача күлмәген киеп килгән.

дә ошап бетмәгән. Бер керәшен дустым белән сөйләшеп алдык, ул да, беренче килеп күргән кешеләр нинди фикердә калыр икән, дип борчыла иде.

Җырагаймасын ара

Инде менә Тырлау аланы буйлап «җөреш»не башлар чак җитте. Елдагыча, бәйрәмдә әллә ничә мәйданчык эшләде. Берәүләр зур сәхнәдә чыгыш ясаучы артистларны күреп калырга ашыкса, икенчеләр шул мәйданчыкларда уздырыла торган төрле уеннар, әйлән-бәйләннәргә таралышты.

Ә кемнәрдер «Димче почмагы»на барып, насыйбын эзләде. Монда килеп, кавышып, гаилә корып, матур тормыш кичерүчеләр 24 ел буена шактый җыелган икән инде. Махсус тактага исемнәрен һәм телефон номерларын язып калдыручылар быел да күп иде. Кем белә бит, атаклы димче Аграфена Васильева кавыштырган парлар тагын да артып куяр әле.

Шулай дип теләдек тә, матур итеп бизәлгән ишегалларын күреп, «җырак араларны җакын итеп», республиканың төрле районнарыннан килгән керәшеннәр белән аралашырга ашыктык. Киемнәреннән алып сөйләшүләренә кадәр һәркайсы үзенчәлекле бит аларның. Питрәч районының Керәшен Сәрдәсе авылыннан килгән Ольга Харитонова авылларындагы һәр йорт тәрәзәсен диярлек бүген дә чигүле пәрдәләр бизәвен сөйләде.

– Без һәр бәйрәмне көтеп алып, бөтен җолаларны да үтәп яшибез. Балаларыбыз, оныкларыбыз да белеп, күреп үсә. Керәшеннәр электән чигүгә оста булган. Бүген дә чигәбез, йортларыбыз күз явын алырлык. Миңа кызыгып, оныкларым да чигүгә тартыла башлады. Күз нурларым – 8 оныгым, 1 оныкчыгым бар минем, – дип сөйләде ул. – Бүгенге бәйрәмгә әбиемнең алача (җитеннән Тегелгән. – **Ред.**) күлмәген киеп килдем. Андый күлмәкне берәүдә дә күрмәдем әле.

Питраудан соң бер атна узуга, Корман боткасы пешерәселәре бар икән әле. «Игеннәр уңсын, яңгырлар яусын, балаларыбыз исән-сау булсын, дип тели-тели пешерәбез. Ботка пешә торган казанга ярманы иң башта авылның беренче нигезендә яшәүче хуҗалар салырга тиеш», – дип аңлатты Ольга түти.

Кукмара керәшеннәре элек-электән киемдә – кызыл төскә, җырларның көйләләренә өстенлек бирә икән.

– Ул җырлар – 1994 елда ук барлыкка килгән «Карендәшләр» ансамбленең йөзек кашы. Шунысы сөендерә: «Карендәшләр»нең баласы – «Тәңкәләр» ансамбленә йөрүче балалар саны да елдан-ел арта. Өлкәннәр һәм үсеп килүче буын арасындагы элемтәләрне җыр һәм моң белән ныгыту – иң үтемле чараларның берседер ул, – дип сөйләде ансамбльнең җитәкчесе Светлана Тимофеева.

Төскә матур, эшкә батыр

Питрауның тагын бер йөзек кашы булган «Керәшен чибәре» бәйгесенең мәйданчыгы яныннан да болай гына узып китә алмадык. Чибәрлекнең нәкъ оясы бит ул! Керәшен кызлары башкалардан сылулыклары белән аерылып торуларын үзләре дә яшерми.

Төп бүләк – «Керәшен чибәре» таҗы өчен бу юлы 12 кыз көч сынашты. Матурлыкта гына түгел, керәшен татарларының һәм башка милләт вәкилләренең йолатрадицияләрен, милли бәйрәмнәрне белү, җыр-биюгә, телгә һәм сүзгә осталык – жюри әгъзалары әнә шулардан чыгып бәя бирде. Ярышның иң кызган мәлендә кызлар янына килеп, тагын да дулкынландырдым, ахры, үзләрен. Ләкин Балык Бистәсе районының Казаклар-Чаллысы авылы кызы Вероника Степанова сер бирмәде.

– Бәйгедә беренче тапкыр катнашуым. Айлар буе әзерләндек, дулкынланабыз, билгеле, – диде ул. – Өстемдәге киемнәрем көч бирә миңа. Тамаксам – әбиемнеке, күлмәгем – җырак түтиемнеке. Гомумән, безнең өйдә җиде буынның киемнәре саклана. Алар һәркайсы үзенчәлекле, тарихлары да шундый кызыклы. Үзебезнең традицион киемнәрне көндәлек тормышта да бик рәхәтләнеп кияр идем мин.

Бәйгедә Вероника «Йолаларны яхшы белүче» номинациясендә җиңде һәм III урынга лаек дип табылды.

Ә «Керәшен чибәре» таҗы бу юлы Мамадышта калды. «Иң-иң»е булып Мамадыш районының Шәдче Башы авылыннан Алёна Евдокимова танылды. «Бүген таҗ алу максатым иде. Үзем өчен горурлык хисе кичерәм», – диде 2022 елның «Керәшен чибәре». Ул шулай ук «Иң җор телле» номинациясендә дә җиңү яулады.

Башка номинацияләрдә җиңүчеләр:

«Иң яхшы җыручы» – Эльза Гордеева (Балык Бистәсе)
«Иң яхшы биюче» – Алена Архипова (Мамадыш)
«Иң сөйкемле» – Светлана Иванова (Мамадыш)
«Халыкчан костюм иясе» – София Комиссарова (Чаллы)
«Этник костюм белгече» – Ксения Александрова (Менделеевск)
«Иң оста пешерүче» – Регина Мухина (Питрәч)
«Иң оста чигүче» – Светлана Егорова (Түбән Кама)
«Иң иҗади» – Лидия Михайлова (Кукмара)
III урын – Вероника Степанова
II урын – Татьяна Ефимова
Мамадыш районының «Керәшен чибәре» – Светлана Иванова.

Тырлау аланында Питрау көнне таң атканчы күңел ачалар дип әйткән идем инде. Үзәк мәйдандагы уеннар иртәнге чык төшкәндә дә бара иде әле. Йокы дип тору юк – бәйрәм булгач, бәйрәм инде.

Көрәшчеләр дә беренче әтәчләр кычкырганчы бил алышты. Инде икенче ел рәттән Питрауның төп батыры исемен Зәй егете Радик Сәлахов яулады. Узган елдан аермалы буларак, быел ул 120 килолы тәкәсен яңа «Lada Largus» машинасында алып кайтып китте. Үсмерләр арасында Актаныш егете Илназ Шәмсиев батыр калды.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 6640 данә
Гомуми тираж – 16052 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 302

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+